Scientific Chronicles of the Turkic World
Төрки дөнья фәнни хроникасы
Научная хроника тюркского мира

# LATEST EVENTS IN 2016

On September 13-18, 2016, Mirphatikh Zakievich Zakiev, Alphiya Shavketovna Yusupova, Gulshat Raisovna Galiullina and Zoya Nikolaevna Kirillova, professors of Tatar Philology Department at Kazan (Volga region) Federal University, took part in the 10th Russian Scientific-Practical Conference "Key Issues of Turkic Language Studies and Orientalism: History, Ethnogeny, Language and Literature of Turkic Peoples in the Crimea" held in Tavrida National University named after V.I.Vernadsky.

The conference was organized by the Faculty of the Crimean Tatars and Oriental Philology of Tavrida National University named after V.I.Vernadsky, the Crimean Historical Museum-Reserve Larishes (Ларишес) with the financial support of the Russian Humanitarian Science Foundation. It attracted scholars from Moscow, St. Petersburg and from the Republics of Tatarstan, Bashkortostan, Chuvashiya, Dagestan and others.

On September 14, during the plenary meeting, M.Z.Zakiev, Doctor of Philology, a member of the Academy of Sciences, spoke about the linguistic traces of ancient Turkic peoples and naming units with Turkic origins. Professor A.Sh.Yusupova, Doctor of Philology, head of the Tatar Philology Department, supervised the work of the section "Turkic Languages Studies" and presented a report on bilingual dictionaries of Turkic peoples. Professor G.R.Galiullina, Doctor of Philology, Head of the Department of Modern Tatar Language and Instruction, spoke about precedent names in modern Tatar. Associate Professor Z.N.Kirillova, Candidate of Philology in the Department of the Tatar Language History and Turkic Linguistics, presented the Scientific Society of Tatar Studies. These presentations were of great interest to the audience.

The 10th Russian Scientific-Practical Conference has united the scholars of Turkic languages, literature, history and culture. They discussed a great amount of issues, sharing results of scientific research, new ideas, and learning the harsh history of the Crimean Tatars.

---

Kazan held a grand meeting devoted to the 25th anniversary of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. Attendees included Mintimer Shaimiev, the First President of Tatarstan, Rimma Ratnikova, Deputy Chairman of Tatarstan State Council, Taliya Habreeva, Vice-President of the Russian Academy of Sciences, Mahmut Gareev, Professor, Russian Army General, Doctor of History and Military Sciences, Engel Fattakhov, Minister of Education and Science in the Republic of Tatarstan, Adel Vafin, Tatarstan Minister of Health Care, and representatives of scientific societies from different regions of Russia, the CIS and foreign countries, researchers and public figures of the Republic of Tatarstan.

The meeting was opened by Myakzyum Salakhov, the President of the Academy of Sciences of the RT, who presented his report "The Tatarstan Academy of Sciences celebrates 25 years of its public service".

Mintimer Shaimiev, the State Counsellor of the Republic of Tatarstan greeted the participants of the meeting on behalf of Rustam Minnikhanov, the President of the Republic, congratulated the audience on the Tatarstan Academy of Sciences anniversary. He also remarked that the past 25 years was a fruitful period for the Academy of Sciences. "By now, we have determined our position in academia, developed a programme till year 2030, and we know what should be done. The thing is that we need to be ready to respond to any challenges to ensure a steady development of the Republic. Moreover, we are expected to be able to provide a foundation for a sustainable development of our Republic. The last is impossible without scientific progress, innovations, and utilizing our scientific potential", he said.

Speaking about the accomplishments of Tatarstan Academy of Sciences, Mintimer Shaimiev also mentioned two projects initiated by A.Khalikov Institute of Archaeology: the 7-volume "History of the Tatars", and the 6-volume Tatar Encyclopedia, published in Russian and Tatar. Mintimer Shaimiev also noted that recognition of the Kazan Kremlin and Bolgar Historical and Archaeological Complex as UNESCO world heritage sites is another accomplishment of Tatarstan scientists.

Mintimer Shaimiev emphasized the role of the Republican scientific community in starting the Bulgarian Islamic Academy, which is under construction at the moment. The academy is intended to offer degrees in Theology and study the academic heritage left by outstanding Tatar theologians of the 17th-20th centuries.

"By now we have gained confidence in the appropriateness of the chosen direction as for all these years we managed to have provided progressive and innovative foundation for the development of our Republic. It is good to know that the decision we took 25 years ago, and which sometimes aroused questions, was correct and stood the test of the time", said the First President of Tatarstan in his concluding speech.

Taliya Habreeva, Vice-President of the Russian Academy of Sciences greeted scientists of the Republic on behalf of the Russian Academy of Sciences and its President, Vladimir Fortov. "The Tatarstan Academy of Sciences was founded in the most difficult time for the Russian academia, the losses we suffered then are still being felt. We especially appreciate the fact that Tatarstan statesmen and scientists were very well aware of their responsibility for the preservation of the scientific potential of the ethnos. In Tatarstan this task was put into practice. It is only now when we fully conceive the depth of wisdom and far-sightedness of the First President of Tatarstan, Mintimer Shaimiev, who made the decision at that difficult time. To a certain extent, it was a heroic act, which now makes it possible for us to say that Tatarstan academia was not depolarized, but developed, thus contributing to the development of the entire country", she said.

A guest from Astana, Timur Kozyrev, a representative of the International Turkic Academy (TWESCO), greeted the audience on behalf of Darkhan Kydyrali, the President of the Academy of Kazachstan. He awarded Mintimer Shaimiev, the State Counselor of the Republic of Tatarstan, with a gold medal of the International Turkic Academy for the work and contributions he made to Turkology, for strengthening the cooperation and extension of cultural ties between nations.

The audience was also addressed by Victor Spinei, Vice-President of the Romanian Academy of Sciences, Zurab Dzhapua, member and the President of the Abkhazian Academy of Sciences, Ibrahim Guliyev, the Vice-President of the Azerbaijan National Academy of Sciences, Abdygany Erkebaev, the President of the National Academy of Sciences of Kyrgyz Republic, Alfis Gayazov, the President of the Academy of Sciences of the Republic of Bashkortostan, Meret Ashyrbaev, the President of the Academy of Sciences of Turkmenistan, Igor Kolodeznikov, the President of the Academy of Sciences of the Republic of Yakutia (Sakha), Yulai Shamil-oglu, Professor of the University of Wisconsin and others.

---

A Big Ethnographic Dictation" was held in all 85 regions of Russia on October 4. The participants of the event were almost ninety thousand people on 800 sites in Russia and two foreign countries, Turkey and Switzerland. The dictation was written on 20 sites in Tatarstan.

In this country, an average score for the dictation was 54 points out of 100. The citizens of the Republic of Tatarstan got the highest average score (81.3). Among three leaders there were also the Kabardino-

Balkar Republic (73.8) and the Smolensk region (71.9). The Amur region showed the lowest average score (39).

"The results of the dictation have clearly demonstrated that we should focus on the issues of studying the history and traditions of the peoples of Russia. We plan to discuss these results with our colleagues from the expert community, the Ministry of Education of Russia and to give greater importance to this issue. I think it would be correct to have a lesson devoted to peoples of Russia in addition to the traditional "Lesson of Peace", which is held in schools on the Day of Knowledge, September 1. And it is desirable that these lessons be regular", said Igor Barinov, Head of the Federal Agency for Ethnic Affairs, commenting on the results of the Big Ethnographic Dictation.

This event will become a tradition and stand on a par with other all-Russian events such as "A Geographical Dictation" and "A Total Dictation".

---

In 2016 the Department of the Tatar language and literature at Miftakhetdin Akmulla Bashkir State Pedagogical University is celebrating the 25th anniversary of its establishment. Last year was marked with the 25th anniversary of the opening of the Tatar division.

Issued in 1990, the act on training teachers of the Tatar language and literature at Miftakhetdin Akmulla Bashkir State Pedagogical University was a response to the challenge of time. Today, the Division of the Tatar language and literature is one of the largest Tatar divisions in the Republic. One hundred and forty seven people are studying there. The Department of the Tatar language and literature, opened in 1991, preserves its best traditions formed over the past two decades. Despite the difficulties the faculty had to face, the department manages to implement all its tasks. It conducts the preparation of highly qualified teachers of the Tatar language and literature. The department has become a scientific-methodical and national-cultural centre. During this period, the department has prepared 1,500 teachers.

In addition to the qualification of "a teacher of the Tatar language and literature", the undergraduates have the opportunity to get a second qualification in the second year of their study. This can be either Russian or English languages, history, law, or psychology. There also exists the Division of Distance Education. An MA course in "Language Teaching in a Multilingual Environment" has been opened. It deals with the issues both of the Tatar language and other native languages learning in a multilingual environment. Besides the Bashkirs and Tatars, the Kazakhs and Tajiks are studying here.

Since 2013, the Department has been working successfully and fruitfully on the research topic "Gabdulla Tukay and Bashkortstan". The memorial room "Gabdulla Tukay in Ufa" has been created and equipped to commemorate the 100$^{th}$ anniversary of the great poet's stay in Ufa. Its activities aim to promote the poet's work and reveal his role in the development of literature of other nations, Bashkir literature and Tatar literature in particular. The organizers intend to make this memorial room a centre, collecting the best methodical recommendations developed by teachers from different educational institutions. These materials, devoted to the study of literature and culture of the peoples of Bashkortstan, their literary contacts and relationships, will be collected to be used in teaching young people to respect their mother tongue. This work will contribute to the strengthening of friendship between peoples, and help systematize modern methods of research in this branch of knowledge under modern conditions.

The All-Russian Scientific and Practical Conference "Current Issues of Studying and Teaching Tatar Philology" was held on the occasion of the anniversary. It was attended by scholars, teachers, postgraduate students, holders of a master's degree and undergraduates. The primary focus was on the work of methodologists: Professor A.Khamitov, Professor S.Safuanov, Professor R.Amirov, Professor H.Lukmanov, Associate Professor M.Mulyukov and the teachers who have made great contributions to the successful development of the Department of the Tatar language and literature. Furthermore, the conference covered the current issues of modern Tatar philology, language and literature teaching in a multilingual environment, features of regional literature learning, comparative and contrastive study of languages, interactions of the Volga and Ural peoples' cultures and the issues of modern cultural linguistics.

The participants received the news about the opening of the scientific and methodological centre the "Kayum Nasyri Institute" with great enthusiasm. The Alumni Festival, masterclasses of teachers, performances by students and actors - all these events added unique colours to the commemorative event held by the Department of the Tatar language and literature.

---

The International Scientific-Practical Conference “Tatar Linguistics in the Context of Eurasian Humanities” was held in Leo Tolstoy Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan (Volga region) Federal University, on 1-4 November, 2016. The conference was dedicated to the jubilees of the prominent scholars: A.R.Tenishev, D.G.Tumasheva, V.Kh.Khakov, L.Z.Shakirova, F.M.Khisamova, F.G.Garipova, A.Asadullin, V.N.Khangildin, G.Sharaf, G.Nugaybek, R.F.Shakirova and F.Sh.Nurieva.

The conference was attended by researchers, teachers and students from Bulgaria, Finland, Turkey, Malaysia, China, Kazakhstan, as well as Russian cities: Saint Petersburg, Moscow, Simferopol, Ufa, Maikop, Volgograd, Izhevsk, Astrakhan and Glazov. The delegates discussed theoretical aspects of linguistics and the Tatar language studies: traditions and innovations, the native language environment, comparative method in studying languages, culture and polylingual education in the globalized world. Young researchers, participating in the conference, keep up the traditions of the Kazan linguistic school. During the conference, round table sessions were mostly focused on current issues of the Tatar language orthoepy and orthography.

---

On November 5 and 6, 2016, premiere concerts of the Tatar Song Festival “Узгэрешжиле” (“The Wind of Changes”) were held on the stage of Kazan Academic State Opera and Ballet Theatre named after M.Jalil. It was an idea of Rustam Minnikhanov, President of Tatarstan, to hold the event with the aim of raising Tatar variety arts to a higher level. The high task, assigned to the organizers of the festival, was to promote the quality of growth of Tatar popular music and pave the way for its integration into the world contemporary culture.

The honorary guests of the first night were the President of Tatarstan Rustam Minnikhanov, the former President of the Republic and State Counsellor of Tatarstan Mintimer Shaimiev, the Chairman of the State Council of the Republic of Tatarstan Farid Mukhametshin, the Minister of Culture Airat Sibagatullin, the Mayor of Kazan Ilsur Metshin, as well as all political and artistic elite of Tatarstan.

As far back as in the spring of 2015, twenty four talented young artists were selected to participate in the project, implemented under the patronage of the President of the Republic of Tatarstan and supported by the Ministry of Culture. Among them were the winners of international competitions, including the participants of the TV project "Voice" and the graduates of Kazan Federal University Yazilya Mukhametova and Zarina Vildanovaa s well as Alina Sharipzhanova, Rumia Niyazova, Aidar Suleymanov, Ilvina, Camille Khaibullin and many others. They performed Tatar folk songs and songs of national composers, whose unchanged melodies and poetic lyrics have been remade on the basis of current trends in art.

Vadim Eylenkrig, a trumpet player, band leader, educator and TV presenter, was employed as the music director of the project, and Yuri Alexandrov, the art director of the State Chamber Musical Theater "St.Petersburg Opera" worked as the production director. The stage design and costumes were made by Victor Gerasimenko, the chief artist of the Moscow Theater "New Opera". Aidar Gainullin, a famous accordion player, academician of Motion Picture Arts, Honored Artist of the Republic of Tatarstan, took part in the concert. Throughout the period of preparation the participants were guided by the Moscow vocal teachers Alexei and Xenia Korobkov and the People's Artist of the RSFSR and RT Venera Ganeeva. Raufal Mukhametzyanov, the director of the Tatar Academic State Opera and Ballet Theatre named after M.Jalil became the general producer of the project.

---

The 5$^{th}$ International Scientific-Practical Forum "Preservation and Development of Native Languages in a Multinational State: Problems and Prospects" was held at the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University, with the assistance of the Ministry of Education and Science of the Republic of Tatarstan, the Institute of Education of the Republic of Tatarstan, the Inter-University Council for the Development of Multicultural Education at the Council of University Rectors of the Republic of Tatarstan.

The forum was attended by over 400 scientists, teaching staff and heads of educational institutions, members of the federal, regional and municipal education authorities, research and other institutions related to the theoretical and practical studies in the area of preservation and development of native lan-

guages and cultures. Among the participants of the forum were graduate students, undergraduates and students of higher and secondary vocational educational institutions of the Republic of Tatarstan, Mordovia, different Russian cities – Moscow, St. Petersburg, Yekaterinburg, Rostov-on-Don, Belgorod, Nizhniy Novgorod, Stavropol, Ufa, Yoshkar-Ola, Cheboksary, Simferopol, Yakutsk, Gorno-Altaisk and others, researchers from the countries of the near and far abroad: Kazakhstan, Azerbaijan, Armenia, Ukraine, Uzbekistan, Turkmenistan, Latvia, Finland, the Czech Republic, Germany, the United States, Cuba, Japan China, Vietnam, Turkey, Iran, etc.

The 5$^{th}$International Scientific-Practical Forum "Preservation and Development of Languages and Cultures" promoted a fruitful exchange of information and research results between scientists from regions of the Russian Federation and the countries of the near and far abroad. The participants of the conference discussed topical issues related to the preservation and development of languages and cultures, cultural and historical environment, artistic education in the context of intercultural communication, as well as the topics related to the study, dissemination and summarization of the best practices in these areas, among which are the following:

- Prospects for the development of native languages and cultures, language planning and legislation;
- State policies, provision of support for preservation and development of native languages and cultures;
- Comparative historical and comparative studies of languages and cultures;
- Linguistic identity in the modern, multicultural space: experience of different republics and countries;
- Problems of training teachers of native languages, languages of the Russian Federation and foreign languages, teachers of music, dance, Fine Arts and their professional development;
- Official, native and foreign language learning in educational institutions of various levels;
- Linguistic picture of the world and the problems of intercultural communication;
- Native languages as a tool of patriotism and tolerance education, development and preservation of peoples' spiritual and material heritage;
- Creation of a multilingual educational environment in educational institutions;
- Issues of preserving an artistic and historical environment of a modern city, etc.

The papers, presented at the forum, reflect the latest scientific achievements and advanced pedagogical experience in teaching and learning languages, literature, music, dance and Fine Arts.

---

The scientific and educational centre of the Kayum Nasyri Institute at the Permanent Representation of the Republic of Tatarstan in St. Petersburg and Leningrad region held the conference “Formation and Development of the Tatar Literary Language”. The conference highlighted the work of prominent Tatar philologists who contributed to the formation of the Tatar language.

Welcome speeches were made by R.N.Valiullin, Permanent Representative of the Republic of Tatarstan in St.Petersburg and Leningrad region, and A.R.Fahrazieva, a methodologist of the “Kayum Nasyri Institute" Center in St.Petersburg.

The conference aroused great interest among the Tatar community of the city. Many young people from St. Petersburg and Leningrad region attended the conference.

In his speech, the Permanent Representative of the Republic of Tatarstan, R.N.Valiullin, raised the issues related to the historical stages of the development and integration of the Tatar language in modern conditions. In conclusion he said: "The development of the Tatar language is a reliable guarantee of social and public stability in the country."

The conference covered the activities of such outstanding scientists as Sagit Halfin, Kayum Nasyri, Galimzyan Ibragimov, Mirfatyh Zakiev, Fleura Safiullina and others.

The preservation of the Tatar language and literature means a fundamental and inevitable interest of the Tatar people in their culture, their faith, which is to be laid in infancy and maintained throughout life.

---

On November 25, 2016, G.Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan hosted the All-Russian Scientific-Practical Conference "Fatih

Amirhan: Life, Creative Work, Oeuvre" dedicated to the 130th anniversary of the famous Tatar literary classic F.Amirhan. The conference was attended by M.Kh.Salakhov, the President of the Academy of Sciences of the RT, G.R.Nazipova, Director General of the National Museum of Tatarstan, G.F.Tuhvatova, Head of the Literary Museum of Gabdulla Tukay, the scientific staff of the museum, the scientists of G.Ibragimov Institute of Language, Literature and Art and Kazan Federal University. As part of the conference a joint project between G.Ibragimov Institute of Language, Literature and Art AS RT and the National Museum of RT was carried out: A new edition of "Hayat", the famous story by F.Amirhan, was prepared and published. The story is based on original texts written by the author's hand in 20 notebooks, six of them had never been published before, they contain the continuation of the story. The staff of the G.Tukay Literary Museum took an active part in the preparation of this publication. The texts are published together with facsimile pages from the notebooks with the autograph of the writer.

---

On November 25-28, 2016, the Fifth Literary Festival "Open Eurasian Literature Festival & Book Forum" was held in London. Its aim is to promote Eurasian literature at the international level. The event, which received the status of "a cultural bridge between the West and the East", was attended by 60 writers from 16 countries. Aliya Karimova (Russia, Tatarstan) has become the winner of the festival in the category "Literary Translations". The poetess from Kazan has translated Narsuluu Gurgubaeva’s poem "Kuttuu үүgө Kabar aytpay, chakyrtpay" ("With the Unexpected North Wind I Came into Your House") (Kyrgyzstan).

*These materials have been prepared by N.N.Shaydullina, Assistant of the State Counsellor of the Republic of Tatarstan, A.H.Ashrapova, Candidate of Philology, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Lev Tolstoy, Kazan Federal University, E.H.Kadirova, Candidate of Philology, Associate Professor at the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Lev Tolstoy, Kazan Federal University; Z.N.Kirillova, Candidate of Philology, Associate Professor at the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Lev Tolstoy, Kazan Federal University; S.V.Karkina, Candidate of Pedagogy, Associate Professor at the Institute of Philology and Intercultural Communication named after Lev Tolstoy, Kazan Federal University.*

# 2016 ЕЛНЫҢ II ЯРТЫСЫНДА БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР

2016 елның 13-18 сентябрь көннәрендә Казан (Идел буе) федераль университетының Г.Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбе укытучылары М.З.Зәкиев, Ә.Ш.Юсупова, Г.Галиуллина һәм З.Н.Кириллова Симферополь шәһәрендә Кырым федераль университетының Таврия академиясендә узган «Тюркология һәм Көнчыгышны өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре: Кырымдагы төрки телле халыкларның тарихы, этногенезы, теле һәм әдәбияты» дип аталган X Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция эшендә катнаштылар.

Конференция В.И.Вернадский исемендәге Кырым федераль университетының Кырым татар һәм көнчыгыш филологиясе факультеты һәм Ларишес «Кырым тарихи музей-тыюлыгы» ярдәмендә оештырылды, финанс ярдәме исә Россия гуманитар фәнни фонды тарафыннан бирелде. Конференция эшендә Россиянең төрле төбәкләреннән: Татарстан, Башкортстан, Чувашия, Дагстан һ.б. республикалардан һәм Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләреннән килгән галимнәр катнашты.

14 сентябрьдә булган пленар утырышта филология фәннәре докторы, академик М.З.Зәкиев Кавказдагы борынгы төркиләрнең лингвистик эзләре хакында сөйләп, тыңлаучыларны төрки нигезле атамалар белән таныштырды. Г.Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбе директоры, филология фәннәре докторы, профессор Ә.Ш.Юсупова «Төрки тел белеме» секциясе эшен алып барды һәм төрки халыкларның ике телле сүзлекләре турында чыгыш ясады. Татар теле белеме кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы, профессор Г.Р.Галиуллина хәзерге татар телендәге прецедент исемнәр хакында сөйләде, ә гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты З.Н.Кириллова Татарларны өйрәнү фәнни җәмгыяте эшчәнлеге белән таныштырды. Югары мәктәбебез галимнәренең чыгышлары тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты.

X Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе төрки халыкларның телен, әдәбиятын, тарихын һәм мәдәниятен тикшерү белән шөгыльләнгән галимнәрне бергә туплап, фәнни тәҗрибәләр белән уртаклашу, үзара фикер алышу, ачы язмышлы Кырым татарларының тарихы белән танышу юнәлешендә гаять зур эш башкарды.

---

Казанда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә нигез салынуның 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булды. Анда Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова, Россия Фәннәр академиясе вице-президенты, РФА академигы Талия Хәбриева, армия генералы, хәрби фәннәр докторы, тарих фәннәре докторы Мәхмүт Гәрәев, ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, ТР сәламәтлек саклау министры Гадел Вафин, Россия, якын һәм ерак чит илләр фәнни берлекләре вәкилләре, республика галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

Җыелыш башында «ТР Фәннәр академиясе – җәмгыятькә 25 ел хезмәт» доклады белән Фәннәр академиясе президенты Мәгъзүм Сәлахов чыгыш ясады.

ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев җыелышта катнашучыларга республика президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән сәламләү сүзе белән мөрәҗәгать итте. Минтимер Шәрипович катнашучыларны юбилей белән котлады, Фәннәр академиясе өчен 25 елның вакыт кына түгел, яхшы юбилей да булганлыгын искәртеп үтте. «Хәзерге вакытта без билгеләнеп җиттек, республикабызның 2030 елга кадәр үсеш программасы бар, без нәрсә эшләргә кирәген беләбез. Иң мөһиме: республика алга таба үссен өчен, безгә заман таләпләренә җавап бирергә әзер булып торырга кирәк. Без исә үсә һәм республикабызның алга таба тотрыклы үсешен тәэмин итә алабыз. Ләкин фәнни-техник алгарыштан, инновацияләр кертүдән һәм фәнни көчләрне куллланудан башка бу мөмкин түгел», – дип билгеләп үтте ул.

Татарстан Фәннәр академиясе ирешкән казанышлар турында сөйләгәндә, Минтимер Шәймиев 7 томлык «Татар тарихы»н, рус һәм татар телләрендә чыккан 6 томлык Татар энциклопедиясен, А.Халиков исемендәге Археология институтын төзүне атады, Татарстан галимнәренең гаять зур хезмәте нәтиҗәсендә Казан Кремле һәм Болгар тарихи-археологик комплексының бөтендөнья универсаль ядкәре булып танылуларын һәм ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирас исемлегенә кертелүләрен билгеләп узды.

Минтимер Шәймиев республикабыз гыйльми берлегенең хәзерге вакытта төзелә торган һәм XVII-XX гасыр күренекле татар теологларының фәнни мирасы нигезендә бүгенге көн өчен дин белгечләрен тәрбияләү бурычын куйган Болгар ислам академиясендә укыту эшен оештырудагы аерым ролен ассызыклап үтте.

«Бу еллар эчендә бездә бөтен нәрсәдә ышаныч барлыкка килде, республикабызның алга бара торган һәм инновацион үсеше тәэмин ителә – болар барысы да бездә көчле рух һәм ышаныч булуы турында сөйли. Шунысы яхшы: безнең тарафтан 25 ел элек кабул ителгән һәм кайвакыт, бәлки, сораулар да тудырган карар дөрес булып чыкты, һәм вакыт та моны раслый», – дип әйтте, сүзен йомгаклап, Татарстанның беренче президенты.

РФА вице-президенты, академик Талия Хәбриева республика галимнәрен Россия Фәннәр академиясе һәм аның президенты – академик Владимир Фортов исеменнән сәламләде. «Татарстан Фәннәр академиясе барлык Россия фәне өчен бөтенләй дә җиңел булмаган чорда төзелде, ул вакытта без кичергән югалтулар әле хәзер дә сизелә, һәм милли фәнни потенциалны саклап калу кирәклеге өчен җаваплы икәнлекләрен аңлаган дәүләт эшлеклеләре һәм галимнәрнең табылуы аеруча әһәмиятле. Россиядә, Татарстанда бу барып чыкты. Авыр вакытта әлеге карарны кабул иткән Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәрипович Шәймиевнең тирән зирәклеген, алдан күрүчәнлеген, мөгаен, без хәзер генә тулы күләмдә аңлыйбыздыр. Бу күпмедер мәгънәдә батырларча адым булды, һәм ул хәзер безгә Татарстанда фәннең сакланып кына калмыйча, үсешкә дә ирешүе, димәк, бөтен ил күләмендә дә белемнәрнең артуына ирешүебез хакында сөйләргә мөмкинлек бирә», – дип билгеләп үтте ул.

Астанадан килгән кунак – Халыкара Төрки академия (TWESCO) вәкиле Тимур Козырев – академиянең президенты Дархан Кыдырали исеменнән сәламләү сүзләрен укыды. ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә ул, тюркологиягә, халыклар арасындагы хезмәттәшлекне ныгытуга, мәдәни элемтәләрне тирәнәйтүгә керткән өлеше өчен, Халыкара Төрки академиянең алтын медален тапшырды.

Җыелышта катнашучылар алдында шулай ук Румыния ФА вице-президенты Виктор Спинеи, Абхазия ФА президенты академик Зураб Джапуа, Азәрбайҗан Фәннәр милли академиясе вице-президенты академик Ибраһим Гулиев, Кыргызстан Республикасы Фәннәр милли академиясе президенты академик Абдыганы Эркебаев, Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Әлфис Гаязов, Төрекмәнстан Фәннәр академиясе президенты Мерет Ашырбаев, Якутия (Саха) Республикасы Фәннәр академиясе президенты академик Игорь Колодезников, Висконсин университеты профессоры Юлай Шамил углы һәм башкалар чыгыш ясады.

---

2016 елның 4 октябрендә Россия Федерациясенең барлык 85 субъектында да «Зур этнографик диктант» акциясе узды, анда Россиянең һәм ике чит ил – Төркия белән Швейцариянең 800 мәйданчыгында 90 меңгә якын кеше катнашты. Татарстанда диктантны 20 мәйданчыкта яздылар.

Диктант өчен ил күләмендә уртача билге – мөмкин булган 100 дән 54 балл. Иң югары уртача баллны (81,3) Татарстан Республикасында яшәүчеләр җыйды. Беренче өчлеккә шулай ук Кабарда-Балкар Республикасы (73,8) һәм Смоленск өлкәсе (71,9) дә керде. Ә иң түбән уртача баллны (39) Амур өлкәсе катнашучылары алды.

Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе Игорь Баринов Зур этнографик диктант нәтиҗәләренә түбәндәгечә аңлатма бирде: «Диктант нәтиҗәләре Россия халыклары тарихын һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү мәсьәләләренә зур игътибар бирергә кирәклекне ачык күрсәтте. Без әлеге нәтиҗәләр хакында экспертлар берлеге һәм Россиянең Мәгариф һәм фән министрлыгы хезмәткәрләре белән фикер алышырга һәм бу темага аерым игътибар юнәлтергә җыенабыз. Белем көнендә – 1 сентябрьдә уздырыла торган һәм гадәткә кергән «Тынычлык дәресе» белән беррәттән, мәктәпләрдә «Россия халыклары» дәресен дә үткәрү дөрес булыр иде, дип уйлыйм. Һәм андый дәресләр даими уздырылсын иде».

Әлеге акция традициягә кертеләчәк һәм «Географик диктант», «Тоталь диктант» кебек гомумроссия чаралары белән бер сафта булачак.

---

Мифтахетдин Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогия университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы үз юбилеен билгеләп үтте. Былтыр татар бүлеге ачылуга 25 ел тулган булса, быел – кафедрага чирек гасыр.

1990 елда, заман таләпләренә җавап буларак, Мифтахетдин Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогия университетының филология факультетында татар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләү буенча татар бүлеге ачыла. Бүген ул, республикадагы иң зур бүлекләрдән исәпләнә һәм анда 147 студент белем ала. 1991 елда ачылган татар теле һәм әдәбияты кафедрасының бай традициясе бар. Аңа күп кенә авырлыклар аша узарга туры килсә дә, ул үз алдына куелган бурычларны үтәп килә: югары квалификацияле татар теле һәм әдәбияты белгечләре әзерли, татар филологиясе буенча әйдәүче фәнни-методик һәм милли-мәдәни үзәккә әйләнеп, үз тарихында 1,5 меңнән артык укытучы-белгеч әзерләгән.

Көндезге бүлектә укучылар, татар теле һәм әдәбияты белгечлегеннән тыш, икенче курста «рус теле», «инглиз теле», «тарих», «хокук», «психология» юнәлешләрен үзләре өстәмә сайлап ала. Читтән торып уку бүлеге эшли. Туган телләрне күптелле шартларда укытырга өйрәтү максатын куйган «Күптелле шартларда тел укыту» магистрлык юнәлеше ачылды. Анда, башкортлар белән татарлардан тыш, төрекләр, казахлар, таҗиклар укый.

2013 елдан кафедра «Габдулла Тукай һәм Башкортстан» фәнни юнәлеше буенча тикшеренү эшләрен нәтиҗәле алып бара. Бөек татар шагыйренең Уфа шәһәренә килүенә 100 ел тулу уңаеннан җиһазланган «Габдулла Тукай Уфада» мемориаль кабинеты әдип иҗатын пропагандалауга, аның халыклар әдәбияты үсешенә, шул исәптән башкорт әдәбияты үсешенә әһәмиятле йогынтысын күрсәтүгә, татар әдәбияты тарихы, Башкортстан халыклары мәдәнияте буенча төрле уку йортларында программа материалларын үтемле үзләштерүгә, халыклар әдәбияты традицияләрендә күчемлелек, әдәбиятлар һәм мәдәниятләрнең үзара йогынтысы һәм бәйләнешләре мәсьәләләрен чагылдыруга, хәзерге заман яшьләрендә туган телгә, халыклар дуслыгына сакчыл карау кебек иң күркәм сыйфатлар тәрбияләүгә, фәнни-тикшеренү эш алымнарын үзләштерүгә хезмәт итәчәк.

Юбилей уңаеннан 21 октябрьдә университетта «Татар филологиясен өйрәнү һәм укытуның актуаль проблемалары» дигән Бөтенрокссия фәнни-гамәли конференция узды. Анда кафедраның татар филологиясен өйрәнүдә һәм укытудагы өлеше, кафедра үсешендә мәгълүм роль уйнаган профессорлар Э.Хәмитов, С.Сафуанов, Р.Әмиров, Х.Локманова, доцент М.Мөлеков кебек педагог-галимнәрнең эшчәнлеге, хәзерге татар филологиясенең актуаль проблемалары, күптелле мохиттә татар теле һәм әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре, Башкортстанның төбәк татар әдәбиятын укыту үзенчәлекләре, Урал һәм Идел буе халыкларының тел һәм мәдәни бәйләнешләре, телләрне чагыштырма-тарихи, типологик өйрәнү, бүгенге заман лингвокультурология проблемалары кебек сораулар үзәккә куелды. «Каюм Насыйри институты» белем бирү һәм мәдәни үзәген ачу тантанага ямь өстәде. Төштән соң татар бүлеген төрле елларда тәмамлаучыларның фестивале, алдынгы укытучыларның осталык дәресләре үтте, артистлар һәм студентлар катнашында зур концерт күрсәтелде. Бәйрәм чараларында Мәскәү, Казан, Алабуга, Төмән, Уфа, Бөре, Стәрлетамак шәһәрләреннән галимнәр һәм республика районнарыннан күпсанлы укытучылар, аспирантлар, магистрлар, студентлар катнашты.

---

